Яшел Үзән районының иҗтимагый-сәяси газетасы Газета 1995 елның 27 сентябреннән чыга № 31 (3664) | җомга **8 август** 2025 ел 16+

# ЯШЕЛ ҮЗӘН

**Дөнья шул ук, үзебез башка «Авыл сулышы».** Үзең җыештырганны пычратасы килми ул. /3

# 11 694

Сугыш турыдан-туры дистәләгән миллион кеше язмышына кагылган. Яшел Үзәннән фронтка барлыгы 36573 кеше алынып, аннан 11 694 кеше кайта алмаган.
Хәзерге вакытта Яшел Үзәндә урам исемнәрендә 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында катнашкан 11 кешенең исеме мәңгеләштерелгән, араларында Советлар Союзы Геройлары да бар.

№31 (3664) 08.08 2025 5

«Яшел Үзән» газетасы | yashel-uzan.ru

# Җиңү солдаты закон сагында

**Геройлар эзеннән.** Иван Караевның тормышы – Бөек Ватан сугышын узган совет солдаты каһарманлыгының ачык үрнәге

**Бөек Җиңүнең 80 еллык юбилее уңаеннан, без ветераннарның каһарманлыгын искә алуны дәвам итеп, бу юлы Яшел Үзән эзтабары Рәхимулла Гарифуллин тәкъдим иткән шәхес турында кыска язма бирәбез. Аның тормыш юлын Яшел Үзәндә әле белмәүчеләр юк түгелдер. Егетнең хәрби хезмәте Кызыл Армиянең фашистларга каршы беренче сугышлары белән туры килә.**



/ Фото Рәхимулла Гарифуллинның шәхси архивыннан алынды.

Хәрби язмышы аны Көнбатыш, Белоруссия һәм Балтыйк буе фронтларына алып килә, анда ул канкойгыч бәрелешләрдә актив катнаша. Сугыш елларында Иван Иванович дүрт тапкыр каты яралана, әмма госпитальләрдә дәваланганнан соң сафка кайта һәм дошманны җиңү өчен көрәшүен дәвам итә.

Күрсәткән батырлыклары өчен ветеран берничә тапкыр орден һәм медальләр белән бүләкләнә. Алар арасында Кызыл Йолдыз ордены да бар. Бу билгеләре аның Ватанга тугрылыгы һәм халык алдындагы бурычы символына әверелә. Әмма сугыш Иван Иванович тормышындагы яңа битнең башы белән генә тәмамлана. Демобилизациядән соң герой өенә кайта һәм үзен законга хезмәт итүгә багышлый. Узган гасырның алтмышынчы елларында ул Яшел Үзән районы прокуратурасын җитәкли, юстициянең өлкән киңәшчесе була. Үзенең эше белән хокук тәртибен ныгытуга һәм туган якта яшәүчеләрнең хокукларын яклауга зур өлеш кертә. Яшел Үзән шәһәре прокуроры булып 1979 елга кадәр хезмәт итә, шуннан отставкага чыга. Иван Караев 1988 елда вафат була. Герой турындагы истәлек яшел үзәнлеләрнең йөрәкләрендә яши, рухи ныклык һәм үз эшеңә тугрылыкныңилһамландыргыч үрнәге булып тора.

# Августта нинди үзгәрешләр кертелә

**Кануннар. 2025 елгы җәйнең соңгы аенда яңалыклар пенсияләрдән алып уенчыкларга кадәр кагыла**

### Пенсияләрне индексацияләү

Түләүләр 80 яшь тулганнарга һәм беренче төркем инвалидлыкка ия булганнарга яңадан исәпләнәчәк. Хезмәтләрен дәвам итүче пенсионерларны узган ел өчен эш бирүче кертемнәре нигезендә планлы индексация көтә. Максималь өстәмә – өч пенсия балы. Бу исәпләү автомат рәвештә алып барыла.

### Банк операцияләренә контроль

Банклар контролендә булырга тиешле финанс операцияләре исемлеге киңәйтелә. Зәркән әйберләр, кыйммәтле металлар һәм асылташлар (шулай ук аларның ватыклары) белән сату итүче шәхси эшмәкәрләр һәм юридик затлар счетларындагы акчалар әйләнешенә һәм табигый алмазлар, кыйммәтле металлдан ясалган истәлекле таңкалар сатып алу һәм сату операцияләренә көчәйтелгән күзәтчелек кертелә.

### Балигъ булмаганнарга счетлар һәм карталар

14 яшьтән 18 яшькә кадәрге яшүсмерләр, үз банк счетларын һәм карталарын ата-аналарының язма ризалыгы белән генә ача алачак. Искәрмә булып рәсми рәвештә эшкә урнаштырылган яки ИП буларак рәсмиләштерелгән 16 яшь тулган балигъ булмаганнар тора.

### СМСларны тыю

Россиялеләр үзләренең элемтә операторы сайтындагы шәхси кабинетында реклама СМС-таратуларын алдырта алачак.

1 сентябрьдән массакүләм шалтыратулардан баш тартырга мөмкин булачак. Тыю урнаштырылганнан соң да спам килсә, моңа Дәүләт хезмәтләрендәге махсус сервис аша шикаять белдереп булачак.